| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Брюшлинского сельского поселения Менделеевского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Бөрешле авыл җирлеге Советы |

| | |
|---|---|
| Р Е Ш Е Н И Е<br>14 .02.2023 ел | К А Р А Р<br>№74 |

"Җир салымы турында" Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советының 2020 елның 25 февралендәге 159 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлеге советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге советының 2020 елның 25 февралендәге 159 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 4 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым түләүчеләр-оешмалар өчен хисап чорлары дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы танылa.»;

1.2. карарның 5 пунктын үзгәртергә һәм бәян итәргә: «салым түләүчеләргә – оешмаларга салым түләүнең агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталы узганнан соң җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасы ¼ күләмендә алдан түләнүен билгеләү, узган хисап чорыннан соң килүче айның 28 числосыннан да соңга калмыйча. Салым чоры нәтиҗәләре буенча түләнергә тиешле салым суммасы үткән салым чоры артыннан килүче елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә».

Салым физик затлар - салым түләүчеләр тарафыннан узган салым чорыннан соң килүче елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Бөрешле авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларга урнаштырып игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://mendeleevsk.tatarstan.ru) «Бөрешле авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Бөрешле авыл җирлеге
Советы рәисе Л.А. Смирнова